ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Красновидовка авыл җирлегенең Красновидово авылында 2024 елда гражданнарга үзара салым кертү турында

2023 елның 06 декабре №5

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Красновидово авылында гражданнар җыены карар кабул итте:

1.2024 елда Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Красновидовка авыл җирлеге Красновидовка авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге уку формасында белем алучы студентлардан, I төркем инвалидлардан тыш, 1000,00 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту (шул исәптән вак таш сатып алу, ташу, салу, юлларны кардан чистарту, ягулык-майлау материаллары, трактор өчен запас частьләр сатып алу);

торак пункт территориясен төзекләндерү (шул исәптән спил, коры агачлар, куаклар кисү; җәйге вакытта территорияне кисү, ягулык-майлау материаллары һәм трактор өчен запас частьләр сатып алу).

«КАРШЫ» «ӨЧЕН»

3. Әлеге карарны адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә:

- ТР, Кама Тамагы муниципаль районы, Красновидово авылы, Совет урамы, 4 нче йорт;

- ТР, Кама Тамагы муниципаль районы, Буртасы авылы, Үзәк урам, 3 нче йорт;

- ТР, Кама Тамагы муниципаль районы, Антоновка авылы, Колхоз урамы, 29а йорт, шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматларының рәсми сайтында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,

Татарстан Республикасы Кама Тамагы

муниципаль районы Красновидовка авыл җирлеге башлыгы А. А. Болтаков